КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 19 май г.Казань № 614

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри үсеше өчен стажировкалар мәйданчыклары системасын төзү һәм аның эшләве турында» 2018 ел, 29 декабрь, 1260 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри үсеше өчен стажировкалар мәйданчыклары системасын төзү һәм аның эшләве турында» 2018 ел, 29 декабрь, 1260 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 15 сентябрь, 836 нчы; 2022 ел, 4 июнь, 520 нче, 2023 ел, 18 апрель, 493 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри үсеше өчен стажировкалар мәйданчыклары исемлеген яңа редакциядә бәя итәргә (карарга теркәлгән);

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри үсеше өчен стажировкалар оештыру һәм үткәрү регламентында:

1 бүлекнең беренче абзацына түбәндәге сүзләр өстәргә:

«күрсәтелгән органнарның ведомство буйсынуындагы дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр (алга таба - ведомство буйсынуындагы учреждениеләр)»;

2 бүлекнең икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«стажировка мәйданчыгы - квалификация күтәрү процессында алынган хезмәткәрләрнең теоретик һәм практик белемнәрен ныгыту һәм үзенә беркетелгән эшне хакимиятнең башкарма органы яки хезмәткәрне квалификация күтәрүгә җибәргән җирле үзидарә органы функционалы нигезендә мөстәкыйль рәвештә башкару буенча аңа тотрыклы күнекмәләр һәм күнекмәләр тәрбияләү максатларында хакимиятнең башкарма органы яки җирле үзидарә органы, ведомство буйсынуындагы учреждение базасында (алга таба - база оешмасы) оештырылган структура;»;

3 бүлектә:

өченче абзацка «җирле үзидарә органы» сүзләреннән соң «, ведомство буйсынуындагы учреждение» сүзләрен өстәргә;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Республика башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары һәм ведомство буйсынуындагы учреждениеләр эшчәнлегенә функциональ анализ ясаучы экспертлар:»;

сигезенче абзацка «җирле үзидарә органнары» сүзләреннән соң « һәм ведомство буйсынуындагы учреждениеләр» сүзләрен өстәргә;

3.1 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Стажировка мәйданчыгын аккредитацияләү максатларында ведомство карамагындагы республика башкарма хакимияте органы, җирле үзидарә органы базасында әлеге бүлектә каралган документлар исемлеге республика башкарма хакимияте органы, тиешле учреждениене гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органы тарафыннан департаментка тапшырыла.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри үсеше өчен стажировкалар мәйданчыклары турындагы бертип нигезләмәдә:

2 бүлекнең икенче абзацына «Татарстан Республикасында» сүзләреннән соң «, күрсәтелгән органнар буйсынуындагы дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр» сүзләрен өстәргә;

5 бүлектә:

5.1 пунктта «республика башкарма хакимият органында, Татарстан Республикасы җирле үзидарә органында» сүзләрен «база оешмасында» сүзләренә алмаштырырга;

5.2.2 пунктның унынчы абзацында «республика башкарма хакимият органнарында, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарында (алга таба - җирле үзидарә органнары)» сүзләрен «база оешмасында» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 29 декабрь, 1260 нчы
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 19 май, 614 нче карары
редакциясендә)

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри үсеше өчен стажировкалар мәйданчыклары исемлеге

| Т/с | Республика башкарма хакимияте органы, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге исеме | Стажировка мәйданчыгы юнәлеше |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы | Норматив хокукый актларның коррупциягә каршы экспертизасы. Норматив хокукый актлар проектларын эшләү |
| 2. | Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы | Җирле бюджетның керем потенциалын һәм аның чыгым вәкаләтләре белән нисбәтен фаразлау<br>Җирле бюджет проектын формалаштыру |
| 3. | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы | Бизнес-проектларны эшләү һәм аларның экспертизасы<br>Бюджет өчен фаразлау параметрларын формалаштыру.<br>Муниципаль районнарның, шәһәр округларының социаль инфраструктура объектлары белән тәэмин ителешен бәяләү |
| 4. | Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы | Мөлкәт һәм җир ресурслары белән идарә итүне оештыру, мөлкәтне һәм җир кишәрлекләрен арендага бирү һәм башкалар |
| 5. | Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты | Икътисадый нигезләнгән тарифны исәпләү |
| 6. | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы | Финанс ярдәмен алуга документлар пакетын рәсмиләштерү һәм аларны экспертизасы |
| 7. | Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат | Зур мәгълүматлар нигезендә идарә итү |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | технологияләре һәм элемтә министрлыгы | |
| 8. | Әлмәт муниципаль районы | Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы эшендә инфокоммуникация технологияләрен куллану |
| 9. | Баулы муниципаль районы | Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу эшләрен оештыру һәм үткәрү<br>Җирле бюджет проектын формалаштыру.<br>Күпфункцияле үзәк эшен оештыру.<br>Гражданнар мөрәҗәгатьләре буенча эш башкаруны оештыру һәм алып бару |
| 10. | Зеленодольск муниципаль районы | Монопрофильле муниципаль берәмлектә яңа инвестиция проектларын гамәлгә ашыру өчен кирәкле инфраструктура объектларын төзү һәм (яисә) реконструкцияләү буенча чараларны финанслау (бюджет чараларын кулланмыйча)<br>Тышкы финанс контроле үткәрү |
| 11. | Питрәч муниципаль районы | Үзәкләштерелгән бухгалтерлык исәбен алып бару.<br>Муниципаль учреждениеләр өчен муниципаль биремнәр формалаштыру (мәгариф бүлеге линиясе буенча) |
| 12. | Саба муниципаль районы | Социаль өлкә учреждениеләрендә транспорт белән йөртүне оештыру |
| 13. | Казан шәһәре | Шәһәр командасы формалаштыру һәм аның белән идарә итү. Хезмәткәрләрне эзләү, җайлаштыру, үстерү һәм кадрлар эшен оештыруның нәтиҗәле системасы.<br>Шәһәр процесслары белән идарә итү. Тормыш һәм үсеш өчен уңайлы киңлек булдыру |
| 14. | Чаллы шәһәре | Инвестицияләр җәлеп итү.<br>Яшьләрне социализацияләү һәм аларны актив җәмгать эшчәнлегенә нәтиҗәле төстә гамәлгә ашыру<br>Муниципаль-хосусый партнерлык проектларын гамәлгә ашыру.<br>Муниципаль эчке финанс контроле һәм сатып алулар өлкәсендә тикшереп тору вәкаләтләрен гамәлгә<br>ашыру |
| 15. | Алабуга муниципаль районы | Финанс-бюджет палатасы эшен оештыру |